РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 20 » 01 2021ел № 32

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 декабрендәге «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 865 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын үтемле һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү «Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында " 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары нигезендә, «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары, 1999 елның 21 октябрендәге «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 ноябрендәге 865 номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга Ютазы

муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Муниципаль Программаның паспорты бүлегендә, Программаны еллар буенча бүлеп финанслау күләмнәре һәм чыганаклары позициясен, яңа редакциядә бәян итәргә:

| Программаны еллар буенча бүлеп финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме 16 965 295 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән: (сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Ел | Барлыгы | Шул исәптән, | | |
| | | | Татарстан Республикасы бюджеты, | җәлеп итүгә планлаштырылган федераль бюджет акчалары <*> | Җирле бюджет |
| | 2020 | 1 670 256 | 1 318 432,33 | 351 823,67 | <*> |
| | 2021 | 1 019 069,1 | 802 720,73 | 216 348,37 | <*> |
| | 2022 | 2 038 138,2 | 1 605 441,46 | 432 696,74 | <*> |
| | 2023 | 4 076 276,4 | 3 210 882,92 | 865 393,48 | <*> |
| | 2024 | 4 076 276,4 | 3 210 882,92 | 865 393,48 | <*> |
| | 2025 | 4 076 276,4 | 3 210 882,92 | 865 393,48 | <*> |
| | Барлыгы | 16 956 295 | 13 356 472 | 3 599 821 | <*> |
| | -------------------------------<br><*> Чараны финанслау күләме ел саен төгәлләштерелергә тиеш | | | | |

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе С.П. Самонина

Н.А. Әбилтарова
2-76-81